ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

05.03.2021 ел Баулы шәһәре №29

2021-2025 елларга «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә һөнәр сайлау» муниципаль программасын раслау турында

В целях формирования личности и выявления у подростков и молодежи профессионального самоопределения в соответствии с желаниями, способностями, индивидуальными особенностями каждой личности и с учетом социокультурной и экономической ситуации в условиях современного общества Исполнительный комитет Бавлинского муниципального района Республики Татарстан

Яшүсмерләрдә һәм яшьләрдә һәр шәхеснең теләкләренә, сәләтләренә, индивидуаль үзенчәлекләренә туры китереп һәм заманча җәмгыять шартларында социомәдәни һәм икътисадый ситуацияне исәпкә алып һөнәри үзбилгеләнешен ачыклау һәм шәхес формалаштыру максатларында Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. 2021-2025 елларга «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә һөнәр сайлау» муниципаль программасын расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының 2021 елның
5 мартындагы 29 номерлы
карары белән расланган

2021-2025 елларга «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә һөнәр сайлау» муниципаль программасы

## I. ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программ атамасы | 2021-2025 елларга «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә һөнәр сайлау» муниципаль программасы (алга таба – Программа) |
| Программага заказ бирүче | Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты |
| Программа координаторы | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының яшьләр эшләре бүлеге» МКУ;<br>«Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ |
| Программаны эшләүче | «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының яшьләр эшләре бүлеге» МКУ;<br>«Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ |
| Программа максаты | Хәзерге заман җәмгыяте шартларында социомәдәни һәм икътисадый вәзгыятьне исәпкә алып, һөнәри үзбилгеләнешкә сәләтле Баулы муниципаль районы гомумбелем бирү учреждениеләре укучыларының шәхесен формалаштыру |
| Программа бурычлары | Программаның төп бурычлары:<br>- яшьләрнең сайлап алынган һөнәр буенча хезмәткә мотивациясен арттырырга;<br>- яшүсмерләрдә һәм яшьләрдә үзбилгеләнүгә ихтыяҗны активлаштырырга;<br>- гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын реаль социаль һәм икътисадый шартларда үз ниятләрен гамәлгә ашыруга юнәлтергә;<br>- үз-үзен анализлау, үз индивидуаль үзенчәлекләрен һөнәри таләпләргә туры китерү буенча белем һәм практик күнекмәләр формалаштыру;<br>- һәр шәхеснең индивидуаль үзенчәлекләре нигезендә һәм заманча җәмгыять шартларында социомәдәни һәм икътисадый вәзгыятьне исәпкә алып, үсмерләрдә һәм яшьләрдә һөнәри үзбилгеләнеш формалаштыруга ярдәм итүче профориентация системасын булдырырга. |

<table>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру сроклары һәм этаплары</td><td colspan="3">2021-2025 еллар</td></tr>
<tr><td rowspan="10">Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре</td><td rowspan="2">Ел</td><td colspan="2">Фаразланган акча күләме, мең сум</td></tr>
<tr><td>Муниципаль район бюджеты</td><td>Внебюджетные источники</td></tr>
<tr><td>2021</td><td>10,00</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2022</td><td>10,00</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2023</td><td>10,00</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2024</td><td>10,00</td><td>-</td></tr>
<tr><td>2025</td><td>10,00</td><td>-</td></tr>
<tr><td>Барлыгы:</td><td>50,00</td><td>-</td></tr>
<tr><td colspan="3">Финанслау күләме – бюджет чыганаклары<br>Программаны финанслау күләмнәре фараз булып тора һәм, тиешле дәрәҗәдәге бюджетларны тиешле елга һәм план чорына формалаштыруны исәпкә алып, ел саен төзәтмә кертелергә тиеш, шулай ук программа чараларын финанслауга федераль һәм республика бюджетларыннан акчалар бүленергә тиеш.</td></tr>
<tr><td colspan="3"></td></tr>
<tr><td>Программаны гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре</td><td colspan="3">Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге үсмерләрнең һәм яшьләрнең һөнәри сайлау ысулларында, үз үсеш перспективаларын планлаштыру һәм үз һөнәри киләчәкләренә тагын да оптимистик мөнәсәбәт формалаштыруда чагыла.</td></tr>
</table>

## II. Гомуми нигезләмәләр

2021-2025 елларга «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә һөнәр сайлау» муниципаль программасы яшүсмерләрнең һәм яшьләрнең шәхесен формалаштыруга юнәлтелгән. Яшүсмер мөстәкыйль рәвештә һөнәр сайлый алмый, чөнки ул әле үз тормышының барлык якларын тулысынча аңларга әзер түгел. Ул өлкәннәр тарафыннан ярдәмгә, психолог-педагогик ярдәмгә, мәктәпнең, гаиләнең, социумның уртак эшчәнлегенә мохтаҗ. Шуңа күрә бүгенге көндә төп бурыч - үсмерләрне һәм яшьләрне белем алуны дәвам итүнең киләчәк вариантларын сайлауга һәм алга таба һөнәри билгеләнешкә әзерләү. Моның өчен үсмерләрдә һәм яшьләрдә һөнәр сайлауга бәйле рәвештә үз-үзеңне һәм эшчәнлекне социаль яктан әһәмиятле эчке (психологик) көйләгечләр формалаштырырга; һөнәри үзбилгеләнештә социаль яктан актив эшчәнлекнең тышкы һәм эчке шартларын тудырырга кирәк.

Профессиональ үзбилгеләнеш - шәхес үсеше процессы, аның эчтәлеге хезмәт дөньясы турында белемнәр системасын формалаштыру, уңай хезмәт юнәлеше,

иҗтимагый әһәмиятле эшчәнлектә гамәли осталык һәм күнекмәләр алудан гыйбарәт. Дөрес итеп һөнәр сайлау һөнәрне уңышлы үзләштерүнең, көндәшлеккә сәләтле профессионал формалаштыруның мөһим шартына әверелә.

## III. Программаның төп максатлары һәм бурычлары

Программаның максаты: заманча җәмгыять шартларында социомәдәни һәм икътисадый вәзгыятьне исәпкә алып, Баулы муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының шәхесен формалаштыру.

Программаның төп бурычлары:

- яшьләрнең сайлап алынган һөнәр буенча хезмәткә мотивациясен арттырырга;
- яшүсмерләрдә һәм яшьләрдә үзбилгеләнүгә ихтыяҗны активлаштырырга;
- гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларын реаль социаль һәм икътисадый шартларда үз ниятләрен гамәлгә ашыруга юнәлтергә;
- үз-үзен анализлау, үз индивидуаль үзенчәлекләрен һөнәри таләпләргә туры китерү буенча белем һәм практик күнекмәләр формалаштыру;
- һәр шәхеснең индивидуаль үзенчәлекләре нигезендә һәм заманча җәмгыять шартларында социомәдәни һәм икътисадый вәзгыятьне исәпкә алып, үсмерләрдә һәм яшьләрдә һөнәри үзбилгеләнеш формалаштыруга ярдәм итүче профориентация системасын булдырырга.

## IV. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программаны финанслау Баулы муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла. Программаның гамәлдә булу чорына финанслауның гомуми күләме - 50 мең сум, шул исәптән:

2021 ел – 10,0 мең сум;

2022 ел – 10,0 мең сум;

2023 ел – 10,0 мең сум;

2024 ел – 10,0 мең сум;

2025 ел – 10,0 мең сум.

Программаны финанслау күләмнәре фараз булып тора һәм, тиешле дәрәҗәдәге бюджетларны тиешле елга һәм план чорына формалаштыруны исәпкә алып, ел саен төзәтмә кертелергә тиеш, шулай ук программа чараларын финанслауга федераль һәм республика бюджетларыннан акчалар бүленергә тиеш.

## V. Программаны гамәлгә ашырудан көтелгән нәтиҗәләр

Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының һөнәрләр белән тотрыклы кызыксынуы формалаштыруда чагыла. Бу - уку йортлары белән танышу, хезмәт базарында конкрет вәзгыять белән танышу; һөнәри үзаң формалаштыру, шәхси һөнәри планны төгәлләштерү.

Мәктәп тәмамлаучылар өчен аеруча актуаль - ситуациядә ориентлаша белү, дөрес һөнәри сайлау ясау. Кешенең һөнәри карьерасы ничек башлануы профессияне дөрес сайлауга бәйле.

Баулы муниципаль районының гомуми белем бирү учреждениеләрендә һөнәри юнәлеш бирү программасын гамәлгә ашыру актуаль булып тора. Хәзерге хезмәт базары яшьләргә яңа таләпләр куя. Яшь кеше үз тормышында һөнәрен берничә тапкыр алуштыруга, яңа эшчәнлек төрләрен үзләштерүгә, мөстәкыйль рәвештә эш эзләүгә һәм хезмәт базарында үзен алга этәрүгә әзер булырга тиеш.

## VI. Программа индикаторлары һәм аларның күрсәткечләре

| № п/п | Индикатор атамасы | Үлчәү берәмлеге | Еллар күрсәткечләре | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2020 | Муниципаль программаны тормышка ашыру еллары | | | | |
| | | | | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 |
| 1. | Программаны гамәлгә ашыруда катнашучы укучылар саны | чел. | 1500 | 1600 | 1700 | 1800 | 1900 | 2000 |
| 2. | Программаның район чаралары саны | ед. | 30 | 35 | 40 | 45 | 50 | 55 |
| 3. | Программаны гамәлгә ашыруда җәлеп ителгән югары уку йортлары саны | чел. | 6 | 8 | 9 | 9 | 9 | 10 |

## VII. Программаны гамәлгә ашыру чаралары

| № п/п | Чара атамасы | Тормышка ашыру сроклары | Чыгымнар суммасы, мең сум | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 | Барлыгы: |
| 1. | ВУЗ, ССУЗ вәкилләре белән очрашулар оештыру һәм уздыру | 2021-2025 еллар | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 10,0 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2. | Төрле һөнәр вәкилләре белән очрашулар оештыру һәм уздыру, шул исәптән оешмада экскурсияләр | 2021-2025 еллар | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 10,0 |
| 3. | Тематик әңгәмәләр, предметлы атналар, декад, олимпиадалар үткәрү | 2021-2025 еллар | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 10,0 |
| 4. | Социаль челтәрләрдә профориентация эше буенча мәсьәләләрне системалы яктырту | 2021-2025 еллар | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 10,0 |
| 5. | Муниципаль районда рәсем, проектлар, иншалар тематик конкурслары үткәрү | 2021-2025 еллар | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 2,0 | 10,0 |
| | Барлыгы: | 2021-2025 еллар | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 10,0 | 50,0 |

______________________